**Материклар, океаннар, халыклар һәм илләр**

473. 2012 нче елның январь азагы февраль башында түбән температура зонасына Россия Федерациясенең төрле өлешләрендә (үзәгендә, Төньяк–Көнбатышта, Идел буенда, Уралда, Себердә, Ерак Көнчыгышта) урнашкан 50дән артык субъекты эләгә. Башкала регионында термометр баганасы -25º-30º ка кадәр төшә. Берничә көн дәвамында терекөмеш баганасының 772 мм тәшкил иткән югары атмосфера басымы күзәтелә. Хакасиядә һаваның температурасы –30º ка кадәр төшә. Якутиядә исә тагын да салкынрак. Укучылар өчен Байкал аръягында бу көннәр ял көннәренә әйләнә. Салкыннар күзәтелү сәбәпле илнең Европа һәм Азия өлешләрендә экологик хәл начарлана. Шунысын да билгеләп китергә кирәк, Себер иксез-чиксез киңлекләрендә урнашуга карамастан, Көнчыгыш Себернең күпчелек шәһәрләрендә, бер үк шартларда, Россиянең Европа өлешендәгегә караганда экологик ситуация күпкә түбәнрәк була.

Ни өчен кышын көчле салкыннар вакытында Көнчыгыш Себернең күпчелек шәһәрләрендә Россиянең Европа өлешендәгегә караганда экологик ситуация күпкә начаррак була? Рельефының үзенчәлегенә бәйле бер сәбәпне һәм Себер шәһәрләрендә электр энергиясе җитештерүгә бәйле бер сәбәпне күрсәтегез. Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка

языгыз, башта биремегезнең номерын күрсәтегез.

474. Кышкы кискен салкынаю кайсы илдә Себер антициклоны йогынтысына бәйле?

1) Украина
2) Монголия
3) Узбәкстан
4) Таджикистан

475. 2007 нче елның гыйнварендә Кейп-Йорк ярымутравында (Австралиянең төньяк-көнчыгышы, Квинсленд штаты) өзлексез яуган яңгырлар су басуга китерә. Ә Австралииянең көньягында (Яңа Көньяк Уэльс һәм Виктория штатлары) һәм континентның үзәк өлешендә бу вакытта корылык күзәтелә.

Кейп-Йорк ярымутравы (Австралиянең төньяк-көнчыгышы) кайсы климатик поясta һәм ни өчен аның территориясендә ел саен гыйнвар аенда көчле яңгырлар күзәтелә?

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремегезнең номерын күрсәтегез.

476. Кейп-Йорк ярымутравында (Австралиянең төньяк-көнчыгышы) көчле яңгырлар инде айдан артык баралар, январь урталарыннан бирле туктамыйлар. Йөз меңләгән чәчү җирләр су астында калган. Әлеге чор өчен көчле яңгырлар гадәти күренеш булса да, җирле халык мондый су басуны инде күптәннән хәтерләми. Коткаручылар гражданнарны аеруча зыян күргән районнардан вертолётлар ярдәмендә чыгарырга мәҗбүрләр. Шул ук вакытта Австралиянең үзәк һәм көньяк – көнчыгыш өлешләрендә моңарчы күрелмәгән эсселек күзәтелә.

Кейп-Йорк ярымутравы (Австралиянең төньяк-көнчыгышы) кайсы климатик пояста урнашкан, һәм ни өчен аның территориясендә февральдә ел саен көчле яңгырлар күзәтелә? Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремегезнең номерын күрсәтегез.

477. Кейп-Йорк ярымутравында атмосферадагы явым-төшемнәрнең уртача еллык күләмен билгеләү өчен бирелгән карталарның кайсын кулланырга кирәк?

**1)** физик

**2)** климатик

**3)** табигый зоналар

**4)** үсемлекләр

478. 2011 нче елның 13 январенда Сицилия утравында Европаның хәрәкәттәге иң эре янартавы (вулкан) Этна уянды. Берничә сәгать буе кратердан лава агымы акты һәм эре ташлар тәгәрәде. Лава атылу сәбәпле җирле хакимият оешмаларына хәтта якындагы аэропортларны ябарга туры килә. Зыян күрүчеләр булмый. Этнаның активлыгы артыннан геофизиклар, вулканологлар күзәтеп торалар. Янартау ел саен диярлек уяна, ләкин Сицилиядә мондый күренеш 150 елга бер кабатлана.

Ни өчен Сицилия утравында вулкан атылу күзәтелә?

479. Кайсы дәүләтнең территориясендә вулканнар атылу ихтималы зуррак?

**1)** Индонезия

**2)** Швеция

**3)** Египет

**4)** Монголия

480. Бирелгән кыскача тасвирламага нигезләнеп, кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил ярымутрауда урнашкан. Ул материктагы илләр арасында территория ягыннан иң зур илләрнең берсе булып тора. Аның территориясенең зур өлешен яссы таулык тәшкил итә. Анда да чүл ландшафты өстенлек итә. Нефть запасларына бай. Илнең төп халкы – гарәпләр.

481. Россиянең туристик фирмалары төрле илләргә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап чыгарганнар. Слоганнар һәм илләр арасындагы бәйләнешне чагылдырыгыз: беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килгән элементны табыгыз.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Сез төньяк балкышны, тауларны, фьордларны, искиткеч матур үзәннәрне, шарлавыкларны күрә алачаксыз! | **1)** | Норвегия |
| | | **2)** | Бөекбритания |
| | | **3)** | Таиланд |
| | | **4)** | Испания |
| **Б)** | Бу ил сезне бөтен яктан гашыйк итәчәк: Урта | | |

| | |
|---|---|
| диңгез климаты да, чиста пляжлар да, урта гасыр шәһәрләре романтикасы да! | |

Таблицага сайлап алган цифрларыгызны тәңгәл килгән хәрефләр астына язып куегыз.

---

482. Җир шарындагы халыкның күпчелеге җир йөзенең кайсы өлешендә яши?

1) Африкада
2) Азиядә
3) Америкада
4) Европада

---

483. Китерелгән кыскача тасвирламага нигезләнеп, сүзнең кайсы ил турында баруын билгеләгез.

Бу ил территориясе буенча дөньядагы иң зур ил санала. Өч океан сулары белән юыла. Коры җирдә бары тик бер ил белән чиктәш. Территориясенең яртысына якын өлеше тормыш итү һәм

эшчәнлек өчен уңайсыз булган климатик пояска урнашкан.

Халыкның 1 $км^2$ га тыгызлыгы якынча 3 кеше. Халык илнең көньяк өлешендә аеруча тыгыз урнашкан.

484. Дөньяда кеше саны иң зур булган ил җир шарының кайсы өлешендә?

**1)** Азиядә

**2)** Америкада

**3)** Африкада

**4)** Европада

485. Кыскача тасвирламасы буенча кайсы ил булуын билгеләгез.

Бу ил Тын һәм Атлантик океаннарга чыга. Аның территориясен Төньяк тропик кисеп үтә. Рельефында таулыклар өстенлек итә. Тауларында әлеге ил урнашкан материктагы иң югары сүнмәгән вулкан урнашкан. Бу ил коры җирдә өч дәүләт белән чиктәш.

486. Кыскача тасвирламасы буенча кайсы ил булуын билгеләгез.

Бу илнең географик урыны үзенчәлекле. Аны берничә океан суы юа. Июльдә анда кыш уртасы. Бу ил урнашкан материкта сүнмәгән вулканнар юк, анда җир тетрәү күзәтелми. Көнчыгыш ярлары буйлап биек булмаган таулар сузыла. Табигатенең үзенчәлеген киң мәйданга таралган чүлләр билгели. Башкаласы иң зур шәһәрләренең берсе булып тормый. Халкының 1 $км^2$ ка уртача тыгызлыгын якынча 4 кеше тәшкил итә.

487. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу илнең территорясе Атлантик океанга чыга. Аның территориясендә әлеге ил урнашкан материкның иң кырый көнбатыш ноктасы урнашкан. Климаты – субэкваториаль. Илнең символы булып, саваннада үсә торган тирәнгә киткән тамырлы, биек баобаб агачлары тора.

488. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу илнең территориясе тулысынча Көньяк ярымшарда урнашкан.

Көнчыгыштан Атлантик океан сулары белән юыла, аның көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш ярлары буйлап салкын агымнарның берсе уза. Территориясе меридиональ юнәлештә сузылган. Көнбатыш чикләре буйлап таулар сузылып ята. Бакыр, тимер, уран, марганец рудалары, табигый газ һәм нефть чыга торган урыннар ачыкланган. Территориясенең зур өлеше далалар (пампалар), ярымчүлләр һәм чүлләр табигый зоналарында урнашкан.

489. Түбәндә бирелгән халыкларның кайсының күчмә терлекчелек - ат, дөя асраучылык, эре һәм вак мөгезле терлек үрчетү традицион шөгыле булып тора?

1) монголларның

2) грекларның

3) молдаваннарның

4) грузиннарның

490. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу илнең үзенчәлеге булып Россия белән чиктәшлеге һәм диңгезгә чыгу юлы булмау тора. Территориясенең күпчелек өлеше диңгез өстеннән 1000 м һәм аннан да югарырак биеклектә урнашкан, кайсыбер тау сыртлары 4000 м һәм югарырак та. Климаты кискен континенталь, температураның тәүлеклек һәм еллык тирбәнеше максималь. Кайсыбер районнарында күпьеллык туңлык яту күзәтелә. Төп ландшафты – коры далалар, барлык территориясенең чиреккә якын өлешен чүлләр алып тора. Халкы урнашуның уртача тыгызлыгы 1 $км^2$ ка якынча 2 кеше. Халыкның күпчелек өлеше будда динендә.

---

491. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар. Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | В «Меңнәрчә елмаю» илендә сез тропик паркта филләр шоуын һәм танылган будда храмын | **1)** | Таиланд |
| | | **2)** | Алжир |
| | | **3)** | Норвегия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күрерсез! | **4)** | Египет |
| **Б)** | Фьордлар буйлап сәяхәт итеп, үзегез өчен безнең илебездәге иң күрекле урыннарны ачыгыз! | | |

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

492. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу илнең территориясе тар полоса булып океан ярлары буйлап сузылган. Монда материкның бу ил урнашкан иң кырый көньяк ноктасы билгеләнә. Территориянең төньяктан көньякка таба гомуми озынлыгы 4000 км дан артык, һәм климатта төньяктагы тропиктан көньякка таба уртачага күчеш күзәтелә. Территорииясенең 3/4 артыгын таулар алып тора. Бу илдә берничә йөз янартау (вулкан) бар, шуларның 40 тан артыгы хәрәкәттәге вулкан.

493. Кайсы илнең территориясендә океан яр буендагы тропик

киңлекләрдә урнашкан чүл бар?

1) Кытай
2) Египет
3) Төркия
4) Намибия

---

494. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар. Слоганнар белән илләрнең бер өлеше булган утраулар арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **УТРАУЛАР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Су астында йөзәргә яратучылар өчен биредә Һинд океанының көмештәй чиста сулы искиткеч лагуналар. | **1)** | Мальдива утраулары |
| | | **2)** | Канар утраулары (Испания) |
| **Б)** | Сезне монда искиткеч комлы пляжлар, мәһабәт таулар һәм Этна | **3)** | Сицилия утраулары (Италия) |
| | | **4)** | Корсика утраулары (Франция) |

янартавының (вулканының) матурлыгы үзенә җәлеп итәчәк!

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

495. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил Тын океанга чыга. Аның территориясендә материкның әлеге ил урнашкан иң кырый төньяк ноктасы билгеләнә. Илнең территориясе өч – экваториаль, субэкваториаль һәм тропик климатик поясларда урнашкан, ләкин табигатенең төрлелеге, нигездә, рельефының төрлелегенә бәйле. Монда тигезлектәге дымлы тропик урманнардан алып таулардагы мәңгелек карлар һәм бозлыкка кадәр булган барлык табигый зоналарны очратырга мөмкин.

496. Утрауларның кайсы экваториаль климатик пояста?

**1)** Мадагаскар

**2)** Калимантан

**3)** Куба

**4)** Тасмания

---

497. Юрта – конуссыман шатёр, ныклык өчен корпусын тукып ясалган бизәкле полоса белән тарттыралар, стеналарын чыпта белән төрәләр, ә конструкциянең үзен тулаем киез белән каплыйлар. Юрта күчмә цивилизациянең иң атаклы казанышларының берсе булып санала. Юрта түбәндә китерелгән халыкларның кайсысының традицион торыр урыны санала?

**1)** бурятларның

**2)** грузиннарның

**3)** молдаваннарның

**4)** болгарның

498. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар. Слоганнар белән илләрнең бер өлеше булган утрау территорияләре арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче

баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Монда сезне рәхәт климатта, алтын комлы пляжларда, мәрҗәннән (коралл) ясалган бакчалы, чиста сулы Тын океанда онытып булмаслык ял көтә! | **1)** | Бөекбритания (Шотландия утраулары) |
| | | **2)** | Филиппин дәүләте (Филиппин утраулары) |
| | | **3)** | Испания (Канар утраулары) |
| **Б)** | Сезне Атлантиканың матур пляжлары һәм тропик җәннәт могҗизалары көтә! | **4)** | Мальдива (Мальдива утраулары) |

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

499. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар. Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Меңьеллык кедрлары, хуш исле цитрус агачлары үсеп утырган иксез-чиксез тигезлекләре, чиста пляжлары булган Атлас таулары – сезгә ял итәр өчен менә дигән урын. | **1)** | Таиланд |
| **Б)** | Табигать тарафыннан тудырылган гаҗәеп күренешләрне – фьордларны, ә кышкы айларда – төньяк балкышын күрәсегез килсә, ял итәргә бирегә килегез. | **2)** | Австралия |
| | | **3)** | Марокко |
| | | **4)** | Норвегия |

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

| А | Б |
|---|---|
| | |

---

500. Кайсы утрауның территориясендә хәрәкәттәге янартау вулкан бар?

**1)** Сицилия

**2)** Ирландия

**3)** Шри-Ланка

**4)** Тасмания

---

501. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Элекке чорда бу ил эре колониаль держава булган. Төп территориясе Көнбатыш ярымшарда урнашкан ярымутрауларны биләп тора. Бу илнең территориясендә ул урнашкан материкның көнбатыш кырый ноктасы билгеләнгән. Ил коры җирдә бары тик бер генә дәүләт белән чиктәш. Анда халыкара туризм алга киткән.

---

502. Төньяк Америкада яши торган хайваннар

**1)** скунс һәм бизон

**2)** бегемот һәм мөгезборын (носорог)

**3)** юлбарыс һәм панда

**4)** коала һәм үрдәкборын

503. Кайсы утрауның территориясендә хәрәкәттәге вулкан бар?

1) Суматра

2) Мадагаскар

3) Шри-Ланка

4) Тасмания

504. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил территориясе ягыннан дөньядагы иң эре ун ил арасына керә. Территориясенең зур өлеше материкның көньягындагы ярымутрауда субэкваториаль пояста. Рельефында тигезлек өстенлек итә, төньягында биек таулар.

505. Кайсы шәһәр дәүләт башкаласы булып тора?

1) Александрия

2) Шанхай

3) Одесса

| | |
|---|---|
| **4)** | Мехико |

506. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләрендәге утрау территорияләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Һинд океанындагы мәрҗән (коралл) утрауларының тиңе юк. Су астында йөзүне яратучыларга көмештәй чиста сулы менә дигән лагуналар! | **1)** | Бөекбритания (Шотландия утраулары) |
| **Б)** | Монда сезгә дымлы тропик урманнар буйлап күпләгән экскурсияләр тәкъдим итәрләр, сез анда леопардлар һәм | **2)** | Мальдива (Мальдива утраулары) |
| | | **3)** | Индонезия (Калимантан утравы) |
| | | **4)** | Яңа Зеландия (Яңа Зеландия утраулары) |

| | |
|---|---|
| орангутаннарны күрә алырсыз! | |

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

---

507. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләрендәге утрау территорияләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез:

беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| <u>**СЛОГАННАР**</u> | | <u>**ИЛЛӘР**</u> | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Куәтле цивилизацияләрнең борынгы шәһәрләре, менә дигән пляжлар, тропиклардагы бай табигать, кактусларның күп төрләре, мәһабәт янартаулар (вулканнар) – болар барысы бергә илебезне туристларның хыялына әйләндерә! | **1)** | Болгария |
| | | **2)** | Италия |
| | | **3)** | Швеция |
| | | **4)** | Мексика |

| | |
|---|---|
| **Б)** | Монда сезне комлы искиткеч пляжлар, мәһабәт таулар һәм Этна янартавының матурлыгы җәлеп итәр! |

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

508. Иң күп халык яши торган ил кайсысы?

**1)** Россия

**2)** Һиндстан

**3)** США

**4)** Япония

509. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән

бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Куе урманнар, чиста сулы күлләр, анда менә дигән итеп оештырылган балык тоту, җәй көне ак төннәр һәм тау чаңгысы курортларындагы йомшак, җем-җем итеп торган кар күпләгән турисларны безнең илгә ял итәргә җәлеп итә. | **1)** | Болгария |
| | | **2)** | Италия |
| | | **3)** | Төркия |
| | | **4)** | Финляндия |
| **Б)** | Карлы Альпның искиткеч күренешләрен таң калып күзәтеп була торган илгә рәхим итегез! | | |

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

510. Кайсы дәүләтнең территориясендә Җир шарындагы иң зур утрау урнашкан?

**1)** АКШ

**2)** Россия

**3)** Дания

**4)** Канада

511. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Шарлавыклар, фьордлар, таулар, бозлыклар һәм диңгез – табигатьтән ләззәт алыгыз! | **1)** | Таиланд |
| | | **2)** | Австралия |
| | | **3)** | Норвегия |
| | | **4)** | Португалия |
| **Б)** | Җылы океан, мәрҗән (коралл) рифлы пляжлар, будда храмнарындагы онытылмаслык атмосферага Сез битараф калмассыз! | | |

| Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз. |
| --- |
| |

512. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
| --- | --- | --- | --- |
| **А)** | Лалә чәчәкләре, җил тегермәннәре, искиткеч замоклар, борынгы шәһәрләр һәм үз территорияләренең диңгез буендагы күпчелек өлешен кире кайтара алган ил! | **1)** | Нидерланд |
| | | **2)** | Исландия |
| | | **3)** | Таиланд |
| | | **4)** | Норвегия |
| **Б)** | Җылы океан, | | |

| | |
|---|---|
| мәрҗән (коралл) рифлы пляжлар, будда храмнарындагы онытылмаслык атмосферага Сез битараф калмассыз! | |

Таблицага сайлап алган цифларны туры килә торган хәреф астына языгыз.

---

513. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Куе урманнар, чиста сулы күлләр, анда менә дигән итеп оештырылган балык тоту, ак төннәре белән танылган илебезгә ял | **1)** | Кытай |
| | | **2)** | Финляндия |
| | | **3)** | Чехия |
| | | **4)** | Германия |

| | |
|---|---|
| | итәргә рәхим итегез! |
| **Б)** | Дөньядагы иң биек таудагы чүлдә, диңгез өсте тигезлегеннән 4000 м урнашкан таулыкта булу мөмкинлеге булган илгә рәхим итегез! |

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

514. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил үзе урнашкан ярымутрауның күпчелек өлешен алып тора. Аның территориясен нуль меридиан кисеп үтә. Илнең төп территориясендәге климат субтропик. Рельефы нигездә таулы. Утрауларында янартаулар (вулканнар) бар. Хуҗалык итүдә мөһим тармак – халыкара туризм.

515. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Лалә чәчәкләре, җил тегермәннәре, искиткеч замоклар, борынгы шәһәрләр һәм үз территорияләренең диңгез буендагы күпчелек өлешен кире кайтара алган ил! | **1)** | Нидерланд |
| | | **2)** | Чехия |
| | | **3)** | Марокко |
| | | **4)** | Норвегия |
| **Б)** | Табигать тарафыннан иҗат ителгән могҗизаларны – фьордларны, ә кышкы айларда төньяк балкышын күрер өчен бирегә килегез! | | |

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

516. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил Европа ярымутрауларының берсендә урнашкан. Зур

булмаган мәйданда коры җир буйлап Россия белән чиктәш. Территориясенең шактый өлешен таулар алып тора. Яр буена якын өлеше буйлап җылы агым уза. Төп табигый байлыклары: елгаларының гидроэнергетик потенциалы, урман һәм балык ресурслары, шельф зонасындагы нефть һәм табигый газ запасы.

---

517. Кайсы шәһәр дәүләтнең башкаласы?

1) Нью-Йорк
2) Одесса
3) Прага
4) Венеция

---

518. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Территориясенең мәйданы һәм халык саны буенча бу ил дөньядагы иң зур илләрнең берсе, материк мәйданының яртысына якын өлешен алып тора. Атлантик океан сулары белән юыла. Монда дөньядагы иң эре иңкүлек һәм иң эре яссы таулык урнашкан. Территориясе буйлап дөньядагы иң күп сулы елга ага.

Ил рудалы файдалы казылмаларга, су һәм урман ресурсларына бай. Эре шәһәрләр күп, аларның төп өлеше яр буена тупланып урнашкан.

519. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу - территориясенең мәйданы һәм халык саны ягыннан үзе урнашкан материктагы иң зур ил. Төньякта иңкү җирләр, калган барлык территориясен диярлек яссы таулык тәшкил итә. Елгалар бик күп. Бу ил урман, су ресурсларына бай; кара һәм төсле металл, нефть запаслары ятмалары ачылган. Әлеге илдә халыкның урнашуында тигезсезлекләр характерлы: көньякта һәм океан яр буйларында халык куе урнашкан.

520. Халык саны иң күп булган ил кайсы?

1) АКШ
2) Россия
3) Һиндстан
4) Бразилия

521. Кайсы шәһәр дәүләтнең башкаласы?

1) Нью-Йорк
2) Монреаль
3) Сидней
4) Вашингтон

522. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар. Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | **ИЛЛӘР** |
|---|---|
| **А)** Безгә елның теләсә кайсы фасылында килегез! Җәен сез Кара диңгез буендагы курортларда, кышын тауда чаңгы шуу курортларында рәхәтләнеп ял итә аласыз. | **1)** Австрия |
| | **2)** Болгария |
| | **3)** Мексика |
| | **4)** Норвегия |

| | |
|---|---|
| **Б)** | Фьордлар буйлап сәяхәт иткәндә, илебезнең иң матур урыннарын ачыгыз! |

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

523. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар. Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Безнең илебездә сезне йомшак Урта диңгез, бай су асты дөньясы һәм Кызыл диңгез экзотикасы көтә! | **1)** | Австралия |
| | | **2)** | Чехия |
| | | **3)** | Мексика |
| | | **4)** | Египет |
| **Б)** | Искиткеч пляжлар, бай тропик табигать, мәһабәт янартаулар – болар брысы бергә безнең илне теләсә кайсы турист өчен хыялга | | |

әйләндерә!

Сайлап алган  цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

524. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил-архипелаг ике океан сулары белән юыла. Аның башкаласы Көньяк ярымшарда урнашкан. Хәрәкәттәге вулканнар бар, җир тетрәүләр еш була. Һава температурасында сезонга бәйле үзгәрешләр күзәтелмәү табигатенең үзенчәлеге булып тора. Көн һәм төннең озынлыгы бертигез диярлек. Бу ил нефть, күмер, табигый газ, бокситлар, бакыр, аккургаш рудалары запасларына, шулай ук урман ресурсларына бай. Халык саны буенча дөньядагы илләр бишлегенә керә.

525. Кайсы утрау территориясенең мәйданы иң зур?

**1)** Ирландия

**2)** Шри-Ланка

**3)** Утлы Җир (Огненная Земля)

**4)** Мадагаскар

526. Халык саны иң күп булган ил кайсы?

**1)** Бразилия

**2)** Индонезия

**3)** АКШ

**4)** Россия

527. Европадагы кайсы елга иң озын елга?

**1)** Идел

**2)** Днепр

**3)** Дон

**4)** Печора

528. Кайсы шәһәр дәүләтнең башкаласы?

1) Венеция

2) Марсель

3) Нью-Йорк

4) Мадрид

529. Кайсы илдә халык саны күрсәткече иң югары?

1) Һиндстан

2) Россия

3) Бразилия

4) Австралия

530. Кайсы илдә халык саны күрсәткече иң югары?

1) Индонезия

2) Бразилия

3) АКШ

**4)** Һиндстан

531. Кайсы ил җир шарының ике кисәгендә (кыйтгасында) урнашкан?

**1)** Бразилия

**2)** Россия

**3)** Һиндстан

**4)** Алжир

532. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАНЫ** | | **СТРАНЫ** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Фьордлар буйлап сәяхәт иткәндә, илебезнең иң матур урыннарын ачыгыз! | **1)** | Греция |
| | | **2)** | Норвегия |
| | | **3)** | Швейцария |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Б)** | Диңгезле, таулы һәм искиткеч субтропик климатлы илгә рәхим итегез! | **4)** | Чехия |

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

533. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | "Көнчыгыш" якты кояш һәм җылы көньяк диңгез хакимлек иткән, тормыш бәйрәмгә әйләнгән илгә – безнең илгә килегез. Антик шәһәр Карфаген белән танышыгыз! | **1)** | Австрия |
| | | **2)** | Мексика |
| | | **3)** | Тунис |
| | | **4)** | Финляндия |
| **Б)** | Ак карлы Альп таулары | | |

|  |  |
|---|---|
| һәм аның искиткеч болыннары белән хозурланып була торган илгә рәхим итегез! |  |

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

534. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Безгә елның теләсә кайсы вакытында килегез! Җәй көне сезне күңелегезгә хуш килерлек Кара диңгез курортлары, ә кышын тауда чаңгы шуу курортлары көтә. | **1)** | Бөекбритания |
| | | **2)** | Болгария |
| | | **3)** | Мексика |
| | | **4)** | Финляндия |
| **Б)** | Искиткеч пляжлар, бай | | |

тропик табигать, мәһабәт янартаулар (вулканнар)– барысы бергә безнең илне туристларның хыялы иленә әйләндерә.

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

535. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **<u>СЛОГАНЫ</u>** | | **<u>ИЛЛӘР</u>** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Диңгезле, таулы һәм искиткеч субтропик климатлы илгә рәхим итегез! | **1)** | Перу |
| | | **2)** | Греция |
| | | **3)** | Финляндия |
| **Б)** | Монда сез дөньядагы иң зур елганың башланган җирендә була аласыз, | **4)** | Монголия |

дөньядагы иң биектә урашкан Титикака күле күренешләре белән хозурлана аласыз!

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

536. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил ярымутрауда урнашкан, Россия белән коры җир чикләре бар. Яр буйларын океан агымының җылы сулары юа. Рельефында таулар өстенлек ала, яр буе линиясе бик нык ергаланган. Бу илнең территориясендә Европаның төньяк иң кырый материк ноктасы урнашкан.

537. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил территориясе һәм халык саны ягыннан дөньядагы иң зур илләрнең берсе. Бер океанның өч диңгезенә чыга. Территориясе буйлап ике бөек елга ага. Дөге, тары, соя, чәй кебек

культураларның туган иле булып санала. Ташкүмер, тимер рудасы һәм күп төрле төсле металларның рудалары чыгарыла.

538. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил-архипелаг – дөньядагы иң алга киткән илләрнең берсе. Территориясенең иң зур өлешен таулар алып тора, җир тетрәүләр еш була, янартаулар (вулканнар) бар. Ил файдалы казылмаларга ярлы. Территориясе бик нык сузылган, шунлыктан климат шартлары бик төрле. Илнең көнчыгыш яры буйлап океанның җылы агымы уза. Ил, төрле хәвеф-хәтәрләргә сәбәпче булган, Тын океан киңлекләрендә ясала торган тайфуннар юлында урнашкан.

539. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу илнең географик яктан урнашуының үзенчәлеге булып, аның ике генә ил (шуларның берсе – Россия) белән күрше булуы һәм диңгезләргә чыкмавы тора. Урта пояснының тәүлеклек һәм еллык температурасында максималь тирбәнешле кискен-континенталь климатта урнашкан. Кайсыбер районнарында күпъеллык туң ята. Төп ландшафты — коры далалар, территориясенең чирек өлешенә якыны чүлләр. Халыкның тыгызлыгы якынча км$^2$ га 2 кеше.

540. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил территориясенең зурлыгы ягыннан дөньядагы иң зур илләрнең берсе. Төньяк ярымшарда урнашкан. Ярларын өч океан юа. Илнең көнбатыштагы өлешен таулар биләп тора. Ул урманнарга, кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләргә, төче су запасларына, төрле файдалы казылмаларга бай. Коры җирдә бары тик бер генә дәүләт белән чиктәш. Башкаласы – шәһәрләре арасыннан иң зурысы түгел.

541. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил Көньяк ярымшарда урнашкан, аның Атлантик океанга чыгу юлы бар. Территориясе меридиональ юнәлештә 3,7 мең км дан артыкка сузылганлыктан өч пояска - тропик, субтропик һәм уртача климатик поясларга урнашкан. Ярлары буйлап океанның салкын агымы уза. Төп табигый байлыкларының берсе – субтропик далаларның уңдырышлы туфрагы. Әлеге табигый зона биредә пампа дип атала.

542. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу илнең, географик яктан урнашуының үзенчәлеге булып, аның Төньяк һәм Көнчыгыш ярымшарларда урнашуы һәм Атлантик

океан диңгезләренең берсенә чыгу юлы булу тора. Әлеге ил коры җир буйлап бары тик ике ил белән генә чиктәш. Илнең территориясендә ул үзе урнашкан материкның иң кырый төньяк ноктасы билгеләнә. Башкаласының атамасы дәүләт атамасы белән тәңгәл.

543. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил материкның төньягына урнашкан. Ул ике океан бассейнына караган диңгез сулары белән юыла. Территориясенең күпчелеген тигезлек биләп тора һәм ул ярымчүл, чүлләр табигый зоналарында урнашкан. Илнең башкаласы - халык аеруча тыгыз урнашкан төньяк өлешендә.

544. Кайсы илнең территориясе мәйданы ягыннан иң зуры?

**1)** Канада

**2)** АКШ

**3)** Россия

**4)** Кытай

545. Африкадагы иң зур чүл ничек атала?

546. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Мәйданы буенча эре әлеге дәүләт Евразиянең көнбатыш яр буйларындагы бер төркем утрауларда урнашкан. Климаты - һава торышы еш алышынып тора торган океан климаты. Илнең төп минераль байлыгы булып, диңгез төбеннән чыгарыла торган нефть һәм газ тора. Дәүләтнең башлыгы – королева.

547. Бирелгән утрауларның кайсысы, Африканың көньяк-көнчыгыш яр буйларына урнашкан?

**1)** Шри-Ланка

**2)** Мадагаскар

**3)** Ява

**4)** Утлы Җир (Огненная Земля)

548. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил көньяк-көнбатыш континентта тар полоса булып, тропик киңлекләрдән уртача киңлекләргә кадәр сузылган. Илнең күпчелек өлешен таулар били; янартаулар (вулканнар) күп, җиртетрәүләр еш булып тора. Төньягында чүлләр. Илнең төп минераль байлыгы – бакыр һәм селитра чыга торган урыннар. Океанның яр буе сулары балыкка бай.

549. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил төньякта югары үсеш алган ил белән чиктәш. Ике океанга чыгу юлы бар. Башкаласы Американың иң борынгы шәһәрләренең берсе; бу илнең территориясендә борынгы цивилизация учаклары сакланып калган. Территориясенең күпчелек өлешен таулар һәм калкулыклар алып тора; җир тетрәүләр еш була, янартаулар (вулканнар) бар. Ил төсле металл рудаларына, нефтькә һәм табигый газга бай.

550. Мәйданы буенча иң кечкенә  материк ничек атала?

551.  Хайваннар дөньясын вәкилләренең кайсы табигый шартларда Австралиядә яши?

| |
|---|
| **1)** жираф һәм бегемот<br>**2)** үрдәкборын (утконос) һәм ехидна<br>**3)** буйвол һәм фил<br>**4)** лама һәм бизон |
| |

552. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Сезне монда борынгы шәһәрләр, гаҗәеп авыллар, матур таулар, Альп күлләре көтә! | **1)** | Канада |
| | | **2)** | Нидерланд |
| | | **3)** | Австрия |
| **Б)** | Җылы зәңгәр сулы диңгез, пляжларында ак ком, тропик бакчалар һәм пальма урманнары - болар барысы күпчелек | **4)** | Филиппин |

туристларның хыял дөньясы!

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

---

553. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил Евразия ярымутрауларының берсенең көнчыгыш өлешендә, субэкваториаль климатик пояста урнашкан. Төньякта халык саны ягыннан иң эре саналган ил белән чиктәш. Территориясенең күпчелек өлешен таулар били, яр буйларын иңкүлекләр (нигездә эре елга дельталарының түбән өлешләрендә) алып тора.

---

554. Кайсы шәһәр дәүләтнең башкаласы булып тора?

**1)** Марсель

**2)** Рио-де-Жанейро

**3)** Мадрид

**4)** Дрезден

555. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу ил Европадагы ярымутрауларның берсендә, аның да көнчыгыш һәм көньяк өлешенә урнашкан. Аның бары тик ике ил белән генә коры җир чикләре бар. Бу дәүләт территориясе составына диңгездәге ике эре утрау керә. Илнең төньяк өлешендә җәй көне кояш төнгә дә батмый, ә кышын поляр төннәр була. Геологик яктан караганда, бу ил территориясенең күпчелек өлеше борынгы кристаллик токымнан торган кыршау эченә алынган. Илнең төньягында эре тимер рудасы ятмалары бар.

556. Кайсы ярымутрау түбәндәге сурәтләүгә туры килә: «Төньяк ярымшарда урнашкан, зурлыгы ягыннан өченче урында торган океан сулары белән юыла. Ярымутрауның көнбатыш һәм үзәк өлешләрен яссы таулар алып тора, көнчыгыш өлештә иңкүлекләр. Территориясенең күпчелек өлеше тропик климатик пояста, чүл ландшафты өстенлек итә»?

**1)** Һинд-Кытай

**2)** Гарәбстан

**3)** Һиндстан

**4)** Флорида

557. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Илнең территориясе ике материкка урнашкан һәм ике төрле океанга караган диңгезләрнең сулары белән юыла. 90% тан артык мәйданы чүлләр зонасында. Хәзерге чорда, нигездә, гарәпләр яши.

558. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Ил Көнчыгыш ярымшарда урнашкан. Территориясе тропик һәм субтропик поясларда, һәм ул ике океан сулары белән юыла. Илнең иң чик көньяк континенталь ноктасы ул ил урнашкан материкның да иң чик көньяк ноктасы булып тора.

559. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Мәрҗән (коралл) рифлы су асты дөньясы матурлыгы белән хозурлан. | **1)** | Австралия |
| **Б)** | Кодрәтле янартауларның (вулканнарның) кырыс холкын тоеп  кара. | **2)** | Монголия |
| | | **3)** | Исландия |
| | | **4)** | Норвегия |

Сайлап алган  цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

---

560. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

Бу илнең территориясе Төньяк поляр түгәрәк белән кисешә, ярларын өч океан сулары юа. Коры җирдә бары тик бер генә дәүләт белән чиктәш. Әлеге ил үзе урнашкан материкта мәйданының зурлыгы буенча беренче урында, халык саны буенча өченче урында тора.

561. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз.

| |
|---|
| Территориясе Төньяк һәм Көньяк ярымшарда урнашкан. Тын һәм Һинд океан сулары белән юыла. Территориясендә җир тетрәүләрнең активлыгы – аның үзенчәлеге булып тор. Анда сүнгән һәм хәрәкәттәге вулканнар күп. |
| |

---

| |
|---|
| 562. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз. Бу илнең территориясе Көньяк тропик белән кисешә һәм ярлары берничә океан сулары белән юыла. Коры җирдә башка дәүләтләр белән чиктәш түгел. Территориясенең күпчелек өлеше саванна, ярымчүл һәм чүл табигый зоналарында урнашкан. Халыкның урнашу тыгызлыгы ягыннан күрсәткече иң түбән. |
| |

---

| |
|---|
| 563. Кыскача сурәтләмәсе буенча кайсы ил булуын ачыклагыз**.**<br>Көнбатыш ярымшарда урнашкан әлеге илнең территориясен Төньяк поляр түгәрәк кисеп чыга. Башка дәүләтләр белән коры җир чикләре юк. Аның территориясенең шактый өлешендә табигый ландшафт кеше аягы басылмаган хәлдә сакланган. Табигатендәге үзенчәлекле ягы итеп, хәрәкәттәге янартаулар (вулканнар) булуны билгеләргә мөмкин. |
| |

564. Төрле илләрнең туристик фирмалары үз илләренә туристлар җәлеп итү өчен слоганнар (реклама лозунглары) уйлап язганнар.

Слоганнар белән илләр арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганадагы мәгълүматны икенче баганадагы ил белән бәйләгез.

| **СЛОГАННАР** | | **ИЛЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Ел әйләнәсендә ап-ак кар каплаган Альп тавы күренеше белән хозурланыгыз! | **1)** | Чили |
| **Б)** | Атлантиканың гаҗәеп чиста пляжларының берсендә коенып ләззәтләнегез! | **2)** | Австралия |
| | | **3)** | Португалия |
| | | **4)** | Австрия |

Сайлап алган цифларны таблицага туры килә торган хәреф астына языгыз.

565. Кайсы материкта халык саны иң азы?

**1)** Австралия

**2)** Евразия

**3)** Төньяк  Америка

**4)** Африка